ГЛАВА БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ УРСАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 12 ноябрь Олы Урсак авылы № 2

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлегенең Чукри-Алан авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп КАРАР КЫЛА:

1. 2024 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә: Чукри-Алан авылы Җәлил урамы, 15а номерлы йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Большерусаковский авыл җирлегенең Чукри-Алан торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Чукри-Алан торак пункты территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум(биш йөз) күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ки торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмиятле гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту? ".

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Русак авыл җирлеге

башкарма комитетына жыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча жибәрергә рөхсәт итәргә.лешәсезме:

« ӨЧЕН» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Олы Урсак авыл жирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга .http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл жирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Олы Урсак авыл жирлеге башлыгы Зиннәтуллин Г.А.